Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Шәһәр тибындагы
Совет поселогы
423060, Аксубай штп,
Советлар урамы, 2 нче йорт
т.2-73-62

Совет поселка городского типа
Аксубаево
Аксубаевского муниципального
района
Республики Татарстан
423060, пгт Аксубаево,
ул.Советская, д.2
т. 2-73-62

---

# КАРАР

17.04.2021 ел №23

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Аксубай штп Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт хакында яңа редакциядәге нигезләмә турында» 2018 елның 23 ноябрендәге 76 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Аксубай штп Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Аксубай штп Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт хакында яңа редакциядәге нигезләмә турында» 2018 елның 23 ноябрендәге 76 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 34 бүлекнең 4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге мәгълүматларны мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру».

1.2 19.3 пунктының 4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatar.ru) урнаштырырга һәм хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай штп башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Аксубай штп башлыгы,
Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Аксубай штп Советы рәисе

К.К. Гилманов